**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

2021 елның 10 феврале 39№

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 06 мартындагы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше нәтиҗәләре һәм 2021 елга республикасының финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары турындагы 2021 елның 04 гыйнвары ПР - 1 номерлы карары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсенең 24,25 пунктларын үтәү йөзеннән, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 06 мартындагы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 55 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Тәртипнең 2 бүлегенең 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «j» пунктчасы белән өстәргә:

«j) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.»;

- 2.1 пунктының d пунктчасы үз көчен югалткан дип таныргa.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджетын формалаштырганда компенсация түләүләре бирү өчен кирәкле акчаларны күздә тотарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов